РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА МОНАШЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МЕНДЕЛЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
423644, Менделеевский район, с. Монашево
ул. Школьная, д 19

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ МОНАШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
423643, Менделеевск районы, Монаш авылы, Мәктәп урамы, 19

Тел. (факс): (85549) 3-73-18 e-mail: Mon.Men@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 елның 13 ноябреннән №3

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Менделеевск муниципаль районы Монаш авыл җирлегенең Актаҗик авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Менделеевск муниципаль районы Монаш авыл җирлеге Уставының 22 ст. нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. 2023 елның 23 нояберендә 10 сәгатьтә Менделеевск муниципаль районы Монаш авыл җирлегенең Актаҗик авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.
2. Җыеннарның барлык этапларын үткәрү урыны итеп Актаҗик авылы, Левовозжайская урамы, 13 йорт адресы буенча урнашкан Монаш авыл мәдәният йортын билгеләргә.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:
«2024 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районының Монашево авылы җирлегенең Актаҗик авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, I-II төркем инвалидлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаиләләреннән, көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, ә күп балалы гаиләләрдән 50% ка киметеп 500 сум күләмендә билгеләргә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә сез ризамы:

1. Правовожайская һәм Левовожайская урамнарының вак таш җәю;
2. Урам яктырту лампаларын урнаштыру.

“РИЗА” «КАРШЫ"

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendsleevsk.tatar.ru. бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Монаш авыл җирлеге башлыгы Р.Ф. Иосифов